ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 декабрь 2025ел № 10835

Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2024 елның 6 декабрендәге 39/4 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 3 декабрендәге 7864 номерлы, 2023 елның 20 июлендәге 6460 номерлы, 2024 елның 18 гыйнварындагы 242 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәгә, «200 000 (ике йөз мең)» сүзләрен «500 000 (биш йөз мең)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов